ЧИСТА ЯЗ

Ял көннәрендә республикада 96 мең кеше өмәгә чыккан

> 2

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«Бюджетның һәр сумы җаваплы караш таләп итә»

> 3

ТАМЧЫДАН – КҮЛ

3 яшьлек Таңсылуның әти-әнисе кешедән ярдәм сораганчы бик озак уйланган

> 4

АРЧА КУЛИБИНЫ

Ризуан Гатауллин барысын да, үзе әйтмешли, кирәксез дип ташлаган тимер-томырдан ясый

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 59 (28832) | Сишәмбе | 26 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АВЫЛДАН СЫЙЛЫ СӘЛАМ

ЯЗГЫ ЯРМИНКӘЛӘРГӘ НӘТИҖӘ

Республиканың зур шәһәрләрендә уза торган ярминкәләр тәмам. Инде нәтиҗәләр ясар чак җитте. Биш ярминкә көнендә 14 млн сумлык азык-төлек сатылган. Шул исәптән 25,3 тонна бәрәңге һәм яшелчә, 6,5 тонна ит, 1 тонна кош ите, 9,3 тонна сөт, 1,1 тонна сыр, 1,2 тонна атланмай, 60 тонна шикәр, 8 тонна он, 4 тонна ярма һәм 72,4 мең данә йомырка җибәрелгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, быел халык аеруча шикәр, он һәм яшелчәләрне күпләп алган. Соңгы атналарда бәрәңге сатып алучылар да арткан. Шуңа күрә әлеге товарлар башка елларга караганда күбрәк китерелгән.

«Ярминкәләрнең социаль әһәмияте зур. Халык сыйфатлы ризыкларны кибет бәясеннән арзанракка сатып ала ала. Быелгы ярминкәләрне дә кертеп, барлыгы 1 млрд сумнан артык продукция сатылды», – ди министр.

Узган атнада «Казан» агросәнәгать паркында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та булды. Әлеге көнне биредә үз продукциясен Саба, Нурлат һәм Балтач районы җитештерүчеләре тәкъдим иткән иде. Президент ярминкә мәйданнарын, агросәнәгать паркы павильоннарын карап чыкты, сатуга куелган продукция һәм бәяләре белән танышты, шулай ук сатучылар һәм сатып алучылар белән аралашты.

– Еш кына, ярминкәләргә өлкән буын йөри, дигән фикер ишетергә туры килә, – ди Лиана Абдуллина. – Мин алай дип әйтмәс идем. Урта буын да күтеп алды аларны. Яшьләрне дә күрергә мөмкин иде. Ни генә дисәк тә, анда бәяләр арзанрак. Мәсәлән, мин чыккан саен кыяр, помидор, сыр, колбаса сатып алдым. Бөтен төр ризыкны сайлау мөмкинлеге зур. Көзен дә яратып йөрим. Тик язгы һәм көзге ярминкәдәге мохит аерыла. Миңа язгысы күбрәк ошый.

Казанлы Гамбәрия Мөхлисова да ярминкәләрне көтеп ала торган булган.

– Бер атнада да ярминкәгә чыкмый калганым булмады, – ди ул. – Атна саен балык, сыр, казылык, кыяр, помидор, яшел тәмләткечләр алып керә идем. Авыл эремчеген дә алмый калмадым, чөнки фермерларныкы үзгә бер тәмле. Орлыклык һәм башлы суган, дөге, бәрәңге дә сатып алдым. Тик бер тапкыр да шикәргә туры килгәнем булмады. Мин чыкканда анысы калмый иде инде.

Сүз дә юк, шәһәрлеләр өчен язгы һәм көзге ярминкәләрдәге бәяләр отышлы. Фермерлар өчен ничек икән соң?

Буа районы фермеры Әлфия Халитова Казан ярминкәләрендә ит саткан. Әлеге вакытта хуҗалыкларында 25 баш терлек бар.

– Ике атнага бер тапкыр Киров районының Батыршин урамындагы ярминкәгә сату белән килдек. Безнең өчен анда сату отышлы. Халык бик әйбәт алды. Итнең, төрле җиренә карап, бәяләрен 360–420 сумга җибәрдек. Итебез бик тәмле, гел бездән генә ала торган клиентларыбыз бар. Килүебезне көтеп торалар. Мондый ярминкәләр күбрәк урыннарда булса, тагын да яхшырак булыр иде, әлбәттә.

Арча районының Күпербаш авылы фермеры Альберт Галәүтдинов та хезмәттәшенең фикерен куәтләде. Ул да «Казан» агросәнәгать паркында үгез ите саткан.

– Без, ит җитештерүче фермерлар, ярминкәләрне көтеп алабыз, чөнки файдасын күрәбез. Бер барганда икешәр түшкә сатып кайта торган идек. Халык яратып ала, безне генә көтеп торучылар да бар. Килограммын 400–420 сумнан саттык. Гадәттә итне халыкка ботлап сатабыз яки кумәртәләп биреп җибәрәбез, – диде фермер.

Ит сатучылар ярминкәләрне көтеп алса да, сөт ризыклары җитештерүчеләр башка фикердә тора. Кайбыч районының «СЛ Молоко» җәмгыяте вәкиле Фидаил Шәрәфетдинов сату нокталарына сөт, эремчек, кефир, каймак, сөт өсте (сливки), йогырт, май алып килгән. Халык аеруча эремчек һәм каймакларын яратып алган икән.

– Без бернәрсә кушылмаган табигый продукт җитештерәбез. Саклану вакытлары да озак түгел. Билгеле инде, бәясен дә бик арзан куя алмыйбыз. Ә халык очсыз әйбер эзли. Табигый продукт яратмаганнан да түгелдер инде алар. Бәлки акчалары да җитеп бетмидер. Ярминкәне аеруча әбиләр ярата бит. Алып барганны сатып кайтырга тырыштык, әлбәттә. Даими клиентларыбыз да бар. Бездән бер тапкыр эремчек сатып алган кеше кабат килә. Гадәттә күләмен сатылган продукциядән чыгып, чамалап алып бара торган идек, – диде ул.

Фидаил Шәрәфетдинов фикеренчә, ярминкә барлык фермерлар өчен дә отышлы түгел.

– Ярминкә безнең ишеләргә табыш китерми, – ди ул. – Беренчедән, продукция күп сатылмый. 25–30 мең сум чамасы. 100 мең сумлык товар сатсаң иде ул. Менә шул вакытта табыш турында сөйләшергә булыр иде. Икенчедән, безгә ярминкәгә машина яллап киләсе. Аның өчен дә түлисе. Өченчедән, ярминкә мәйданнары күбрәк булырга тиеш, дип саныйм. Әлегә халык аларга туристик сәфәргә килгән кебек кенә йөри. Дүртенчедән, ярминкәдә сата торган җитештерүчеләргә продукция бәяләренә 15–20 процент кына булса да өстәмә хак куярга рөхсәт булсын иде, – ди ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ТУКАЙ – КҮҢЕЛЛӘРДӘ

Татарстан Республикасы Президенты РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВның Туган тел көнен һәм Габдулла Тукайның тууына 136 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле милләттәшләр!

Сезне Туган тел көне һәм татар әдәбиятының классигы, «шигърият күгендәге кояшыбыз» Габдулла Тукайның тууына 136 ел тулу уңаеннан тәбрик итәм.

Туган тел бәйрәме күп еллар дәвамында Габдулла Тукайдан – бәрәкәтле милли җирлектән күтәрелеп, зур әдип булып җитешкән, таланты белән халкыбызның рухи дөньясын яктырткан шәхес образыннан аерылгысыз кабул ителә. Чөнки аның шигърияте кыска, әмма гамьле, мәгънәле тормышы дәвамында газиз туган телебездән, халкыбызның гореф-гадәтләреннән илһамланды.

Бу иҗатның феномены – гаҗәеп дәрәҗәдә милли рухлы, бер үк вакытта башка милләт һәм дин вәкилләренә дә якын-үз булуындадыр. Күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин сүзләре белән әйткәндә: «Тукай иҗатына хас югары рух, интернациональлек – аның үз халкына булган ихлас мәхәббәтенең, сукырларча түгел, бәлки аңлы яратуының бер күрсәткече. Шагыйрьнең башка халыкларга карата олы хөрмәтен нәкъ менә шул аңлы, бернинди хорафат катнашмаган мәхәббәт саклап килде».

Республикада яшәүче барлык халыклар вәкилләре өчен Туган тел көненең әһәмияте бик зур, аларның һәммәсенә ул бердәй якын һәм кадерле. Бәйрәм көннәрендә дөньяга сибелгән татарларның рухи-мәдәни үсешкә, милли тәңгәллекләрен саклауга, бердәмлеккә игелекле омтылышлары яңа яңгыраш ала. Милли-мәдәни күптөрлелекне, илебезнең барлык халыклары һәм этник берлекләренең кабатланмас үзенчәлекләрен, үзлеген саклауны да максат итеп куйган Россия халыкларының мәдәни мирасы елында бу тантананың яңадан-яңа мәгънә төсмерләре ачыла.

Татарстанда, Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә Туган тел көнен һәм Габдулла Тукайның тууына 136 ел тулуны бәйрәм итү татар телен һәм мәдәниятен тагын да популярлаштыруга, җәмгыятьтә тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга ярдәм итәр дип ышанам.

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Тәрбия

Иске яңа традиция

Киләсе уку елында Татарстан мәктәпләрендә яңа традиция кертеләчәк. Һәр уку атнасы Россия һәм Татарстан флагларын күтәрүдән башланачак. Россиянең мәгариф министры Сергей Кравцов тәкъдиме белән кертелгән әлеге чараның әһәмияте нидә?

«Татар-информ» / С. Камалетдинов

Сергей Кравцов 2022 елның 25 апрелен Россия дәүләт флагын күтәрүнең Бердәм көне дип игълан итте. Шул уңайдан Казанның 187 нче лицеенда узган тантаналы чарада республиканың мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да катнашты.

– Мондый чарага ихтыяҗ күптән бар иде. Бүген укучыларда туган илебезгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек, хөрмәт хисләрен тәрбияләү аеруча мөһим. Дәүләт символларыбыз – флаг, гимн, гербта Россия тарихы чагыла. Ә үткәнен һәм бүгенгесен белмәгән шәхес киләчәген төзи алмый, бу – күптән билгеле хакыйкать, – диде ул тантаналы чарада. – Мондый тәрбия чаралары без мәктәптә укыганда да бар иде. Уку көненең флаг күтәрүдән башлануы бүгенгедәй хәтеремдә. Аны спортта, иҗатта аерылып торган иң лаеклы мәктәп укучылары гына күтәрә иде. Мондый күркәм традицияне торгызу – балаларны шәхес буларак формалаштыруда яхшы тәрбия чарасы да, укучылар өчен этәргеч тә. Мондый чаралар кешеләрне берләштерә, ил үсешенә тагын да зуррак өлеш кертүгә омтылыш бирә.

Министр Россия флагын 187 нче номерлы лицей президенты, күпсанлы олимпиадалар җиңүчесе Арина Смирнова белән бергә күтәрде. Татарстан флагын күтәрү мөмкинлегенә исә лицей директоры Гөлнара Галиева белән берлектә мәктәпнең актив укучысы Булат Хәлиуллин ия булды. «Без инде бу вазыйфаны иң алдынгы укучылар башкарачагын хәбәр иттек. Шуннан соң укучылар: «Киләсе атнада флагларны кемнәр күтәрәчәк?» – дип кызыксына башлады», – диде Гөлнара ханым.

Укучыларның үзләре белән дә аралаштык. Алар, лицей директорының сүзләрен хуплап: «Россия һәм Татарстан флагларын күтәрү мөмкинлеге сине башкалардан өстен күрсәтә, чөнки ул мөмкинлек иң лаеклыларга гына бирелә», – диде.

Уку атнасын флаглар күтәрүдән башлауны лицей укытучылары да хуплый. «Балаларда туган җиребезгә, кече Ватаныбызга карата мәхәббәтне менә шундый чаралар ярдәмендә тәрбиялибез дә инде», – диде татар теле укытучысы Ләйсән Абакаева.

Бу традиция көндезге мәктәп яны лагерьларында, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының профильле сменаларында дәвам итәчәк. Ә инде 1 сентябрьдән республиканың барлык мәктәпләрендә дә атна саен уздырылачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Дәүләт Думасы Рәисе:

Бу – махсус хәрби операция. Әгәр Россия тулы масштаблы сугыш алып барса, барысы да күптән беткән булыр иде. Россия солдатлары һәм офицерлары кеше үтерми, ә үзләрен корбан итеп, тыныч халыкны азат итәләр.

(Шәхси телеграм-каналыннан)

ТАТАРСТАНДА – ЭШ

22 апрельгә республикада 10757 эшсез кеше теркәлгән. 1 март белән чагыштырганда, бу 515 кешегә күбрәк. «Работа в России» порталы мәгълүматларына караганда, Татарстанда 60790 эш урыны бар.

Җитештерү (20,4 мең эш урыны)	34%
Төзелеш һәм күчемсез милек (8,3 мең эш урыны)	14%
Транспорт (4 мең эш урыны)	7%
Сәламәтлек саклау (3,1 мең эш урыны)	5%
Фән һәм мәгариф (3 мең эш урыны)	5%

Үзгәрергә

Җанны талкый һаман заман уе,
Төште инде сагыш йөзләремә...
Яшәп булмый элек яшәгәнчә, –
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!

Яшәп булмый элек яшәгәнчә,
Таң шәфәгы минем күзләремдә.
Нур өстисем килә туар көнгә...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Нур өстисем килә туар көнгә,
Нур саласым килә сүзләремә.
Итәгемнән тарта кара төннәр...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Итәгемнән тарта
Кара төннәр...
Ышаналмыйм кайчак түзәремә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Басмак булам
Заман эзләренә.
Алдан бара, әйдәп,
Тукай рухы...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Алдан бара, әйдәп,
Тукай рухы,
«Хөр мәмләкәт» –
Хәзер сүздә генә.
Тукай үзе дәшә кебек бүген:
«Кирәк сезгә, кирәк үзгәрергә!»

Ил үзгәрсен өчен, иң әүвәле
Үзебезгә кирәк үзгәрергә.

Разил ВӘЛИЕВ.
Апрель, 2022 ел

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

МАКРОН КАЛА, ФӘЛӘСТЫЙНДА ХӘЛ АВЫР...

Үткән атнада дөнья җәмәгатьчелегенең игътибары Франциягә юнәлде. Президент сайлауның икенче туры, әгәр дә француз фашистлары лидеры Марин Ле Пен җиңә калса, Европакүләм сәясәттә зур кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин иде. Традицион рәвештә Россиягә симпатия белән караучы Ле Пен Мәскәү белән якынаюны хуплый, санкцияләргә каршы чыга… Әмма аның җиңүгә шанслары аз иде. Беренче турда Макроннан аз гына калышса да, ярыштан төшеп калган башка партия лидерлары, нигездә, халыкны Ле Пенга каршы тавыш бирергә чакырдылар. Бигрәк тә Жан-Люк Меланшон – сул карашлы француз сәясәтчесе, икенче турда катнашу өчен бераз гына тавыш җитеп бетмәгән лидер – үз сайлаучыларын Мариннан йөз чөерергә өндәде. Дөресен генә әйткәндә, ярыш лидерларының берсе дә артык популярлык белән аерылып тормадылар. Үткән атна дәвамында кандидатларның икесен дә кире кагып, урамнарга чыккан французлар байтак булды. Әмма ике сөйкемсезнең берсен сайларга туры килде. Якшәмбе кичендә үк Макронның 58 процент тирәсе тавыш белән җиңүе мәгълүм булды. Ле Пенга 42 процент калды. Ул җиңелде, әмма яулаган тавышлары саны француз җәмгыятендә нацизм идеяләренең шактый ук тамыр җибәрүен күрсәтә, милли өстенлек идеяләре тарафдарларының демократик юл белән хакимлекне бик җиңел ала алуларын раслый. Кайчандыр Франция дилбегәсен үз кулларында тоткан социалистлар һәм республикачыларның беренче турда бик аз тавыш җыюы да Парижда сәяси зәвыкларның бик нык үзгәрүен күрсәтә.

Украина мәйданындагы конфликтның бар игътибарны яулавы Фәләстыйн туфрагында кискенләшкән көрәшне күләгәдә калдыра. Анда сионистлар вәхшәте градусы, рамазан ае керү белән, яңа баскычка күтәрелде. Газзә секторы авиация һөҗүмнәренә дучар ителә, җавап итеп, гыйбриләр өстенә кулдан җыелган ракеталар оча. Конфликт, гадәттәгечә, изге Әл-Әкса мәчете тирәсендә кискенләшә. Якшәмбедән дүшәмбегә каршы кичтә фәләстыйнлылар тагын ике ракетаны уңышсыз очырдылар. Берсе Газзә чикләрендә үк төште, икенчесе дә ерак оча алмады. Әмма төнлә, көтмәгәндә, Ливаннан да Израильнең төньягындагы Шломи торак пунктына ике ракета очып килде. Израильнең ракета һөҗүменә каршы тору системалары эшләмәгән, хәтта ракета һөҗүме турында хәбәр итәргә тиешле сиреналар да кушылырга өлгермәгән. Залп белән атучы иске «Град» системасыннан җибәрелгән ракеталарның килеп төшүен сионистлар рәсми рәвештә раслады. Әмма дөнья җәмәгатьчелеге көрәшнең бу этабы турында берни дә белми диярлек, чөнки хәлләр матбугатта яктыртылмый. Бары тик гарәп телле «Әл-Җәзира» гына фәләстыйнлылар кичергән вәхшәтне киң тасвирлый. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе шимбә көнне Катар телеканалын карады. Моңарчы тәүлек дәвамында Украина мәйданында барган вакыйгаларны сюжет итеп әйләндергән «Әл-Җәзира» Фәләстыйннан дәвамлы репортажлар тапшыра иде.

Сәяси шахмат тактасында ат йөрешләре һәм рокировкалар ясау остасы булып танылган Әрдоган атна ахырында Россиянең һәм хәрби, һәм гражданлык очкычларының Төркия күгеннән Сүриягә очуын тыйды. Босфор бугазы һәм Дарданелла хәрби кораблар өчен ябылган иде, хәзер самолетлар белән дә Сүриягә очу кыенлашты. Россиянең Хмеймимдагы хәрби базасы исә даими ярдәмгә мохтаҗ.

Россиядә

ТАШТАН КӘГАЗЬ ҖИТЕШТЕРЕРБЕЗМЕ?

Россиядәге эчке вазгыять махсус хәрби операциянең барышы белән тыгыз бәйләнгән. Безнең тормышның барлык аркау һәм буй җепләре көнбатыш чикләрдәге вакыйгалар тәэсирендә тукыла. Дүшәмбе иртәсе Украина белән чиктәш Брянск өлкәсендә нефть базасындагы зур янгын турында хәбәр белән башланды. ТАСС андагы резервуарларга ут кабуын хәбәр итә. Янгынга «югары рангтагы» дигән бәя бирелде. Янгын алдыннан куәтле шартлау тавышлары ишетелде дип әйтүчеләр бар. Бу юллар язылганда, вакыйганың башка нечкәлекләре мәгълүм түгел.

Төркиянең Тышкы эшләр министрлыгы Россия белән Украина арасында озакламый тынычлык урнашу ихтималы турында рәсми хәбәр таратты. Аны министр Мәүлет Чавушуглы журналистларга Латин Америкасына очып баручы самолет бортыннан җиткерде. Чавушуглының сүзләрен көндәлек төрек газетасы Sabah цитата итеп китерә, әмма Мәскәүдән дә, Киевтан да моны раслаучы рәсми хәбәрләр ишетелми.

Көнбатыш күпме генә тырышмасын, әлегә Россияне икътисади блокадага алып бетерә алмый. Себер углеводородларына мохтаҗлык үз сүзен әйтә. Европага газ да, нефть тә, хәтта ташкүмер дә бик кирәк. Акрынлап алардан баш тарту сәясәте алып барыла барылуын. Бөекбританиядә яңа ташкүмер шахталары ачу мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Моннан берничә ел элек үк инде Камбрия графлыгында күмер чыгару проекты эшләнгән булган, әмма экология өчен җан атучы көчләр тырышлыгы белән ул өстәл тартмасына салынган. Хәзер шуны яңадан күтәреп азапланалар.

Углеводородлар акчасы мул керүгә карамастан, безне икътисади кыенлыклар эзәрлекли. Доллар совет казылыгы шикеллегә әйләнде: арзан, әмма табып булмый. Банкирлар, бу хәл тиз генә бетмәс, диләр.

Хезмәт базарында хәл киеренке. Эшсезлек зур түгел түгелен, әмма рәсми рәвештә эшле дип саналучыларның байтагы ял итә. Базарда – эш бирүчеләр диктаты: хезмәт хакын азрак тәкъдим итәләр, халык риза булырга мәҗбүр. Вакансияләр саны кими дип әйтәләр.

Импорт һәм экспорт статистикасы яшерелде. Таможня федераль хезмәте моны, санкцияләр темасына матбугатта спекуляцияләр булмасын өчен эшләнә, дип аңлата. Дәүләт Думасы депутаты Оксана Дмитриева «Сәүдә һәм түләү балансындагы уңай сальдо безнең өчен файдалымы соң?» дигән сорауны күтәреп чыга. Углеводородлар сатып, алар урынына банк хисабындагы валюта гына импортлауның хәвефле булуын, реаль икътисад өчен кирәкле товарлар кайтартуны арттыру кирәклеген искәртә.

Икътисадчы Алексей Елсуков исә «РИА Новости» атналыгына таштан кәгазь җитештерү идеясен җиткерә. Известьтан һәм агулы булмаган полимерлардан агачтан алынган целлюлозага көндәш булырлык кәгазь җитештерү мөмкин икән. Офис кәгазен дә, китап баса торганын да, хәтта бәдрәф кәгазен дә. Шәп идея инде шәплеккә, әмма җиһазларны каян алабыз, проект өчен күпме акча кирәк, аны күпме вакытта тормышка ашырып була – берсе дә әлегә мәгълүм түгел.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ШУЛ УК ЮЛДАН

Ашхабадта Татарстан белән Төрекмәнстан арасындагы хезмәттәшлекне үстерү турында сөйләштеләр. Сәфәре барышында Президент Рөстәм Миңнеханов бу илнең яңа җитәкчесе Сердар Бердымөхәммәдов белән очрашты һәм аны сайлауда ышанычлы җиңүе белән котлады.

tatarstan.ru

«Узган ел безнең товар әйләнеше күләме 77,5 млн доллар тәшкил итте, бу күрсәткечләрне арттыру өчен мөмкинлекләр зур», – диде Рөстәм Миңнеханов һәм нефть чыгару, газ җибәрү, автомобиль, авиация, судно төзелеше, химия продукциясе белән тәэмин итү юнәлешләрен телгә алды. Сердар Бердымөхәммәдов исә Татарстан белән тыгыз хезмәттәшлек традициясен дәвам иттерергә әзер булуын белдерде.

Бүген Ашхабадта Татарстанның алдынгы компанияләре – «Татнефть», КамАЗ, «КЭР-холдинг»ның филиаллары эшли. Килешү буенча Төрекмәнстанга 2 меңгә якын «КамАЗ» автомобиле юлланган. «Татнефть» «Төрекмәнәбит» белән актив хезмәттәшлек итә. Казан вертолет заводы Төрекмәнстанга халыкка ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен «АНСАТ» һәм МИ-17-1В вертолетлары, ә Яшел Үзәндәге М. Горький исемендәге завод А 145 проекты буенча ике тизйөрешле пассажир судносы эшләп җибәрде.

Татарстан Президенты Төрекмәнстан делегациясен Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган чараларга чакырды.

Ашхабадта Рөстәм Миңнеханов илнең элеккеге башлыгы Гурбангулы Бердымөхәммәдов белән дә очрашты һәм Татарстан – Төрекмәнстан хезмәттәшлеге мәсьәләләренә шәхси игътибары өчен рәхмәт белдерде. «Без Төрекмәнстан җитәкчелегенә сезнең илдә яшәүче татарларга ярдәм итүләре өчен рәхмәтлебез. Бездә дә төрекмән милли-мәдәни мохтариятенә зур игътибар бирелә», – диде Президент.

НЕФТЬЧЕЛӘР СӨЕНЕЧЕ

Казанда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында «Татнефть» җәмгыяте директорлар советының чираттагы утырышы узды.

Утырышта 2022 елның беренче кварталында «Татнефть»нең бюджет үтәлеше нәтиҗәләре турында мәгълүмат тәкъдим ителде һәм 2022 елның май аена бюджет расланды.

Очрашуның санлы мәгълүматларына килгәндә, «Татнефть» компанияләр төркеменең сатудан кергән табышы 59 процентка арткан һәм 1265 млрд сум тәшкил иткән. Чиста табыш 198 млрд сумга кадәр арткан. Моннан тыш «Татнефть» төркеменең гомуми салым күләме 2 мәртәбә артып, 710 млрд сум тәшкил иткән. Инвестицияләр күләме артуын да әйтәләр: бу юлы 18 процентка артып, 121 млрд сумга җиткән.

Ел нәтиҗәсе буларак, «Татнефть» бизнесның барлык юнәлешләре буенча да күрсәткечләрен яхшыртуга ирешкән. Әйтик, нефть чыгару – 7, нефть продуктларын чыгару һәм аларны ваклап сату – 11,5, шин продукциясен җитештерү – 14, электр энергиясе эшләп чыгару 19 процентка арткан. 2022 елда «Татнефть» геологик разведка эшләренә 6,6 млрд сум (Татарстан буенча – 3,2 млрд сум, республикадан читтә – 3,4 млрд сум) инвестицияләр җәлеп итәргә ниятли.

Сүз уңаеннан, бу көнне Хөкүмәт йортында «Татнефтехим-инвест-холдинг» җыелышы да узды. Татарстан Президентына республикадагы нефть предприятиеләре эшчәнлеге һәм яңа проектлар турында хисап тоттылар.

Республикада бу елның беренче кварталында нефть чыгару – 20, нефть эшкәртү 10 процентка арткан. Татарстанның нефть, газ, химия комплексының төп предприятиеләре 2022 елның беренче кварталында җитештерү күләмен, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 9,1 процентка арттырган.

Беренче кварталда нефть, газ, химия комплексы продукциясенең кайбер төрләренә бәя арту күзәтелде. Компанияләр эшенә продукцияне читкә чыгару, чит илдә җитештерелә торган эшләнмәләр сатып алу, аларны кайтару вакыты озайтылу кебек сәбәпләрнең тискәре йогынты ясавын әйттеләр.

Нотариат көне белән!

Татарстанның юстиция министры Рөстәм ЗАҺИДУЛЛИН газетабыз аша Нотариат көне белән котлады.

«Заманча нотариат – дәүләт хокукый системасының һәр гражданның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауның гаранты булып торучы мөһим, кирәкле институты. Татарстан Республикасы нотариуслары компетентлы булулары, һөнәри осталыклары һәм сайлаган һөнәрләренә тугрылыклары нәтиҗәсендә законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга, хокукый культура дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итәләр, – диелә котлауда. – Күпкырлы һөнәри эшчәнлегегез барлык бурычларны да уңышлы хәл итүгә китерсен һәм бөтен ил рейтингларында Татарстан позициясен арттыруга ярдәм итсен иде!»

Тынычланыр чак түгел

I квартал нәтиҗәләре буенча Татарстанның берләштерелгән бюджетына 93,2 млрд сум акча кергән, шулардан 85 млрд – республика бюджетының үз керемнәре. Саннарга карап тынычланырга хакыбыз юк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов финанс, казначылык һәм салым органнары киңәшмәсендә шулай дип белдерде.

– Үзгәрешләр начар түгел, әмма безнең моңа карап тынычланырга хакыбыз юк. Вазгыять начарланыр дигән фараз бар һәм, әлбәттә, без моңа әзер булырга тиеш, – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов. – Икътисадыбыз һәм безнең предприятиеләр моңа кадәр күрелмәгән басым кичерә. Санкцияләр күп нәрсәләрне үзгәртеп оештыруны мәҗбүр итә.

Рөстәм Миңнеханов хәбәр иткәнчә, федераль исемлеккә Татарстанның система барлыкка китерүче 59 оешмасы кертелгән. Шуларның өзлексез эшләвен тәэмин итү мөһим. Тармак министрлыкларыннан һәм район җитәкчеләреннән бу юнәлештә аеруча игътибарлы булуны үтенде Президент. Финанс мәсьәләләрен дә күз уңыннан ычкындырмаска кирәк.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, санкцияләр аркасында, кайбер предприятиеләр эшлекле активлыгын киметә.

Аларга дәүләт ярдәм итәргә тиеш. Юкса эшсезләр саны артмагае.

– Бурыч – эш урыннарын саклап калу. Хәзер тулы булмаган эш көнендә хезмәт итүчеләр саны 5,7 мең кеше, якын арада әлеге күрсәткеч артырга мөмкин, – диде Президент. – Предприятиеләрдәге торгынлыкның зуррак проблемалар китереп чыгаруы ихтимал. Законсыз башкарыла торган хезмәт мөнәсәбәтләрен киметү буенча эшне көчәйтергә кирәк. Беркем дә тикшерми икән, тәртипсезлек башлана.

Президент искәрткәнчә, республикада салым буенча әҗәтләр күрсәткече үсә. I квартал нәтиҗәләре буенча ул 10,4 млрд сум тәшкил иткән (узган ел белән чагыштырганда 15 процентка күбрәк). Бюджетка салым бурычының иң зур үсешенә юл куйган тармаклар арасында төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык, сәнәгать предприятиеләре, шулай ук транспорт өлкәсе предприятиеләре бар.

Республикада салым җыю эше турында тулырак Россия Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин сөйләде.

Аның сүзләренчә, 2022 елның I кварталында, узган елның шушы ук аралыгы белән чагыштырганда, салым җыю 1,5 мәртәбә арткан һәм 317 млрд сумга җиткән. Шуның белән бергә салым түләүчеләрнең бурычы да үскән: 2021 елның беренче айлары белән чагыштырганда, 1,4 млрд сумга күбрәк. Моңа юл куймаска кирәклеген искәртте идарә башлыгы. Өстәп, шуны да әйтте: физик затлар арасында әҗәтлеләр саны 200 меңгә кимегән. Салым түләүчеләрдән килгән шикаятьләр дә әзәйгән. 2021 ел белән чагыштырганда, 7 процентка. Салым салу юнәлешендә бизнесның суд бәхәсләре саны да 18 процентка кимегән.

Теманың дәвамы 3 нче биттә >

БАШТА – ӨМӘ, АННАН – БҮЛӘК

Чистарту икеайлыгы

Шимбә көнне Татарстан халкы республикакүләм өмәгә чыкты. Казанда ул Урицкий, Горький, Тинчурин, Җиңү, «Крылья Советов», «Континент», «Сосновая роща», «Калейдоскоп», «Комсомолец» паркларында, «Ак чәчәкләр» бульварында, Комсомол күле пляжында, «Казан» гаилә үзәге янында, Горки-Әмәт урманында узды.

tatarstan.ru

«Крылья Советов» паркында өмә уен рәвешендә үткәрелде. Биредә 235 команда катнашты. Һәр командада – дүртәр кеше. Алар чүпләрне җыеп кына калмадылар, төрләргә аерып, шуның өчен баллар да алдылар. Кыска гына вакыт эчендә «Чиста уеннар»да 247 капчык чүп җыелды. Ул капчыкларны икенчел эшкәртүгә җибәрделәр.

– Республика халкына чисталыкка битараф булмаган өчен рәхмәт әйтәсем килә. Чистарту өмәләренә йөрүчеләр елдан-ел арта. Барыбызны да экология берләштерә, – ди Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков.

Өмәгә чыгар өчен көне дә матур иде. Ничек өйдә ятарга кирәк! Казанда яшәүче Лилия Насыйрова әнә шулай ди. Ул иртәдән эштә икән.

– Гаиләбез белән башта йортыбыз янында җыештырдык. Аннары паркка килдек. Оештыручылар халыкны җәлеп итә белә. Уеннар булгач, үзең дә сизмәстән чүпкә үреләсең, – ди ул.

Лилия укытучы булып эшли икән. Укучыларын да табигатьне сакларга, якларга өйрәтә. Тик менә борчуы бар: берәүләр җыештыра, икенчеләр иртәгәсен үк шушы чиста урынга чүп ташлый. «Кеше хезмәтен хөрмәт итсеннәр иде», – ди ул.

Казанның Карбышев урамында яшәүче Сәлимә Шакировага – 72 яшь. Ул бер ел да өмәләрне калдырмый. Үз йортлары янындагы чисталыкны кайгырта.

– Беренче катта торгач, йорт каршындагы җиргә чәчәкләр утырта башладым. Хәзер инде күршеләр килеп рәхмәт әйтә. Шөкер, йорттагы балалар да чәчәкне өзми, урлап алып китүчеләр дә юк, – ди ул. – Без – авылда туып-үскән кешеләр. Гомерем буе эшсез тора алмадым. Бабам исән чагында бакчада эшләдек. Хәзер инде ялгыз йөрү кыенлашкач, аны саттык.

Районнарда да бу елларда халык мәш килеп эшләде. Мамадыш районының Түбән Яке авылында яшәүче Мусиннар ел саен капка төпләрен, елга буйларын чистарта.

– Инешебездә ни генә акмый. Ташу белән китәр әле дип, нәрсә генә ташламыйлар. Әнә шулай сулыклар пычрана да инде. Без көчебездән килгәнне эшлибез. Урамдагы чүпне җыябыз, – ди ул. – Безнең авылда пычрак капка төбе, чүпкә баткан йорт тапмыйсың. Көннәр җылытуга, авыл кешеләре йорт тирәләрен, урамнарны ялт иттереп җыештырып ала. Урамда кәнфит кәгазе дә ташлаучы юк.

Ә менә Сарман районының Ләшәү Тамак авылында яшәүче Ханнановлар, чүп җыеп, бүләк тә ала әле.

– Яз җитүгә, тирә-якны чистартасың бит инде ул. Без бәләкәйдән эшләп үстек. Балаларымны да шуңа өйрәтәм. Башта өй тирәсен җыештырабыз, аннан инде авылдагы инешләрне, ташландык җирләрне, чишмәләрне чүп-чардан арындырабыз. Өмә булганга түгел, үзебезгә кирәккә чыгабыз без анда. Үз мисалыбызда балаларыбызны тәрбиялисе килә, – дип сөйли Илнур. – Бервакыт кызым дуслары хакында кайтып сөйләде. Баксаң, алар чүпне урамга ташлап бара икән. «Ник ташлыйсың?» – дигәч, «Сез бит – чүп җыючылар, җыештырырсыз әле», – дип җавап биргәннәр. Менә шул сүз мине гаҗәпләндерде. Үземчә кимсетү дип тә кабул иттем. Әмма күңелне төшермәдем. Мондый сүз әйткән балаларны да чүп җыярга өйрәтәм әле, дидем. Моның өчен әллә ни эшләмәдем. Эшләгәнебезне видеога төшереп, төрле бәйгеләргә җибәрә башладым. Беренче елны ук балаларым җиңде. Аларны бүләкләделәр. Моны яшьтәшләре дә күрде. Узган ел кызыма җәйге ялга юллама да бирделәр.

Казанда үткән өмәдән дә күп кенә җитез кешеләр зур бүләкләр белән кайтып китте. Александр Шадриков әйтүенчә, ял көннәрендә республикада яшәүче 96 мең кеше өмәгә чыккан. Полигоннарга барлыгы 89 мең кубометр көнкүреш калдыклары җыелган. Бу – 18 мең «КамАЗ» дигән сүз. Икеайлык башланганнан бирле чүплек урыннары турында хәбәр итеп, министрлыкка 746 мөрәҗәгать килгән. Күзәтү органнары 1291 кагыйдә бозу очрагын теркәгән. Алар тиешсез урынга төзелеш, авыл хуҗалыгы, азык-төлек калдыкларын ташлау һәм чүп чыгармауга бәйле. Шуннан 781 чүплек юкка чыгарылган, 664 кеше җавапка тартылган. Күктән тә күзәтүләр алып барыла. Бер көндә генә республиканың 10 районында 192 чүплек теркәлгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«БЮДЖЕТНЫҢ ҺӘР СУМЫ ҖАВАПЛЫ КАРАШ ТАЛӘП ИТӘ»

Кичә Татарстан тупланма бюджетын беренче кварталда үтәү йомгаклары буенча республика киңәшмәсе узды. Финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИНнан икътисади санкцияләрнең төп финанс документын үтәүгә ничегрәк йогынты ясавы һәм ел азагына кадәр бурычлар турында сораштык.

:: Радик Рәүфович, беренче өч айда бюджетның керем өлешенә бәйле хәлләр ничегрәк тора?

– Беренче кварталның гыйнвар – февраль айларында бюджет уңышлы үтәлде. Мартта исә керем керү берникадәр акрынайды. Саннарга килсәк, Татарстан тупланма бюджетына барлыгы 85,0 миллиард сум күләмендә салым һәм салым булмаган керем алынды. Республика бюджеты 72,3 миллиард сумга үтәлде. Җирле бюджетларда 12,7 миллиард сум тупланды.

Республика тупланган керем күләме буенча Россия субъектлары арасында унынчы урында торса, Идел буе федераль округында – беренче.

:: Барлык салымнар планлаштырылган күләмдә җыеп алынган, дигән сүзме?

– Шулай дип әйтергә мөмкин. 2022 елның 1 кварталында салым түләү динамикасы уңай. Өч айда 34,5 миллиард сум күләмендә табышка салым тупланды. Ә бу салым тупланма бюджетның төп салымнары арасында иң мөһим урын алып тора һәм аның чагыштырма өлеше 41% тәшкил итә. Шуңа күрә безнең министрлык та, тармак министрлыклары да иң күп салым кертүче төп предприятиеләргә даими игътибар биреп, аларның эшчәнлеген күзәтеп тора, килеп туган мәсьәләләрне шунда ук тиз генә хәл итәргә тырыша. Анализ нәтиҗәләре, апрельдән башлап, табышка салым буенча тискәре фаразга этәрә. Агымдагы елда салымның чама белән 21 миллиард сумга кимрәк керүе көтелә.

Физик затлар керемενә салым динамикасы уңай: 1 кварталда 23,8 миллиард сум күләмендә керде. Шул ук вакытта федераль законнарда күздә тотылган салым «вычет»лары буенча кире кайтарылган сумма арту күзәтелә, аның үсеш темпы салымныкыннан зуррак.

Апрель аенда исә, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, салым керү темпы кимү күзәтелә. Бүгенгә якынча 800 миллион сум күләмендә салым кереме тоткарлана.

Шул сәбәпле, салым керемен планлаштырылган күләмдә алу өчен, ведомствоара комиссияләр эше көчәйтеләчәк.

:: Керемнең һәр төре билгеле бер үзенчәлекләргә ия булып, тирәнтен анализ таләп итә. «Ваграк» булсалар да, бик мөһим башка салымнарны үтәү ничегрәк?

– Бюджетка һәрбер сумны кертүгә, шулай ук аннан нәтиҗәле файдалануга чиктән тыш җаваплы карарга кирәк. Шуңа күрә салым «вак» була алмый, аның һәркайсы зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, үзмәшгульләр керемενә салым тулысынча республика бюджетына алынып, соңыннан бюджетара трансфертлар рәвешендә җирле бюджетларга кире кайтарыла. Шуңа күрә әлеге салым буенча бурычны киметү һәм аның үсүенә юл куймау кирәк. Әмма бүген, кызганычка, ул һәр ай саен үсеп бара һәм 3 ай эчендә 12,4 миллион сумга артып, 59,6 миллион сумга җитте инде.

:: Чыгышыгызда муниципалитетларга финанс ярдәме алу өчен яңа шарт кертелү турында әйтеп үттегез. Нинди яңалык бу?

– Агымдагы елдан башлап, салымнар буенча бурыч үсүгә юл куймау һәм хезмәткәрләрнең салым бурычын каплавы муниципалитетларга финанс ярдәме бирүдә өстәмә шарт булып торачак.

Гомумән, недоимка белән эшләү катлаулы геосәяси вазгыятьтән чыгу буенча төп бурычларның берсе булып тора. Безнең барыбызга да аны ничек тә киметү юнәлешендәге чараларны киңәйтергә кирәк.

1 апрельгә салым түләүләре буенча недоимка, банкротлыкка чыккан һәм бетерелгән оешмаларныкын исәпкә алмыйча, 4,5 миллиард сум тәшкил итә. Узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 792 миллион сумга күбрәк бу.

:: Беренче кварталда бюджетның керем өлеше күләме аның чыгым өлешен үтәү мөмкинлеге бирдеме?

– Узган елдан ел башына калган бюджет средстволары һәм 1 кварталдагы керемнәр хезмәт хакын бөтен өстәмәләре белән тулысынча һәм вакытында түләү, барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның беренче чиратта кирәкле чыгымнарын җитәрлек күләмдә финанслау мөмкинлеге бирде.

Татарстан тупланма бюджеты чыгымнары 95,1 миллиард сум тәшкил итте. Республика бюджеты чыгымнары – 80,1, җирле бюджетлар – 33,3 миллиард сум күләмендә.

Хезмәт хакын түләү буенча «май указлары»н тормышка ашыру бюджетны чыгымнар буенча үтәүдә төп мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Агымдагы елда илкүләм проектларны тормышка ашыру дәвам итә. Татарстан Республикасында 2022 елга әлеге чараларга барлыгы 29,4 миллиард сум каралган, шул исәптән федераль бюджеттан – 19,1, Татарстан бюджетыннан – 10,3 миллиард сум. 1 кварталда аларны гамәлгә ашыруга 2,7 миллиард сум тотылды.

:: Республиканың дәүләт бурычы күләме байтак икәнлеген беләбез. Бүгенгә аның тәгаен күләме нинди, һәм без агымдагы түләүләрне башкара алачакбызмы?

– Быел 1 апрельгә Татарстан Республикасының дәүләт бурычы 98,1 миллиард сум иде. Шул исәптән федераль кредитлар буенча – 86,7 миллиард сум, дәүләт гарантияләре буенча – 11,4 миллиард сум.

Республика 1 кварталда инфраструктура проектларын тормышка ашыру өчен каралган 10,4 миллиард сум күләмендәге кредитның беренче траншын – 731 миллион сумын алды.

Татарстан, федераль кредитлар буенча түләүләрне вакытында күчереп, бурычларын вакытында үти.

:: Геосәяси вазгыятьнең бюджетны үтәүгә ничегрәк йогынты ясавына да тукталып үтсәгез иде.

– Беренче кварталда бюджетны үтәүгә йомгак ясап, шуны басым ясап әйтәсем килә: тулаем 2022 елга бурычлар куйганда, һәр көн саен тискәре тенденцияләрнең үсүе күзәтелеп торган бер мәлдә, агымдагы хәлләр исәпкә алынырга тиеш. Икътисадка һәм предприятиеләрнең хәленә геосәяси вазгыять, санкцияләр, хуҗалыкара элемтәләрнең өзелүе йогынты ясый. Нәтиҗәдә барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга керемнәр кими. Шул сәбәпле, бюджетларның тиешле балансын тәэмин итү өчен, бюджет чыгымнарын экономияләү һәм оптимальләштерү чараларын хәл итү буенча эшләргә тиешбез. Шулай булганда, бюджетның сыйфатлы итеп үтәләчәген ышандырырга мөмкин.

Әңгәмәдәш – Диләрә СӘГЪДӘТШИНА

Җиңүчеләр

Солдат хәбәрсез югалмаган

Бу бәйрәмгә һәркем үзенчә, күңеле кушканча әзерләнә. Тарих институтында узган утырышта исә тагын бер кат Бөек Ватан сугышына кагылышлы саннарны барладылар, моңа кадәр төен булып торган мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләделәр. Алар арасында, мөгаен, «Хәтер китабы» редакциясе эшче төркеменең элеккеге җитәкчесе, бүген 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының өлкән фәнни хезмәткәре Михаил Черепанов күтәреп чыккан проблема иң саллысы булгандыр.

Ул «хәбәрсез югалды» дигән төшенчәне «сугыш кырыннан әйләнеп кайтмады» дип үзгәртү тәкъдиме белән чыкты. Бу мәсьәләне хәл итү өчен, дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итәргә кирәклеген әйтте. Аның фикер йөртүенчә, 77 ел буена өйгә кайта алмаган солдат берничек тә югалган булып санала алмый. Ватан сакчылары һәлак булган, яралардан яки әсирлектә үлгән булып саналса, бу аларның үзләре өчен дә, балалары-оныклары өчен дә гадел булыр иде. Вице-премьер Ләйлә Фазлыева да бу тәкъдимне гадел дип ассызыклады һәм аның буенча эшләргә вәгъдә бирде.

Шунысы шатландыра: республикада инде менә күп еллар эзләнү эшләре бер минутка да тукталып тормый. Михаил Черепанов бәян итүенчә, 2022 елның апрель аена 1939–1945 елларда (совет-фин сугышын да кертеп) фронттан кайтмаган 377593 татарстанлының исеме ачыкланган. 354 якташыбызга Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Аларның 185е республикада туган, 169ының тормышы Татарстанга бәйле (яшәгән яки укыган). Документлардан күренгәнчә, тагын 217 кеше Герой исеменә тәкъдим ителгән. Тик, ни кызганыч, бу югары исем теге яки бу сәбәпләр белән бирелми калган. 51 кеше Дан орденының тулы кавалерлары булган.

Михаил Черепанов шулай ук Татарстанда туган Советлар Союзы Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары турында китап чыгару тәкъдимен дә әйтте. Ә менә Казанда туып-үскән Геройлар турында мондый китап дөнья күрде инде.

Утырышта фашистлар оештырган «Идел-Урал» легионына эләккән әсирләр турында да аерым сүз булды. Аларга карата мөнәсәбәттә гаделлекне һәм дөреслекне торгызырга кирәк дигән фикергә килделәр. Чөнки фронт сызыгы аша үткәндә, татар-башкорт легионерларының күбесе партизаннар ягына күчә. Бер өлеше дошман белән бәрелеш вакытында һәлак була. Ничек кенә булмасын, алар Җиңүгә үзләренең өлешләрен кертәләр. Моның шулай икәнлеге документлар нигезендә расланган. Бу җәһәттән дә Ләйлә Фазлыева, Җиңү көненә эш планы төзегәндә, белгечләрнең тәкъдимнәре искә алыначак, дип вәгъдә бирде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

САН

Татарстаннан 700 меңгә якын кеше фронтка китә, шуларның 350 меңе һәлак була яки хәбәрсез югала.

Союз буенча саннарга килгәндә исә, алар гел үзгәреп тора һәм, ни кызганыч, гел өскә таба үрмәли. Сталин җитәкчелек иткән чорда бу сан – 7 млн, Брежнев вакытында 20 млн була. Үзгәреш елларында исә төгәллек кертелә. Армия генералы Мәхмүт Гәрәев җитәкләгән комиссия мәгълүматлары буенча, бу сан 29 млн 784 мең 200 кешегә җитә. 2015 елда Россия Оборона министрлыгы СССРда барлык югалту 26,6 млн дип игълан итә.

ИҢ ЭЛЕК БУ ТЕЛ БЕЛӘН...

«Татар-информ» / С. Камалетдинов

Балалар бакчаларында татар мохитен ничек булдырырга? Татар теле дәресләрен ничек кызыклы һәм нәтиҗәле итеп алып барырга? Казанның «Бала-Сити» мультилингваль балалар бакчасында үткән беренче республикакүләм «Туган тел фест-2022» фестивалендә бу һәм башка сорауларга җавап эзләделәр.

Татар телендә белем бирүче тәрбиячеләр һәм укытучылар фестивале Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә оештырыла. Республиканың иң актив, алдынгы тәрбиячеләре һәм укытучылары аралашу, тәҗрибә уртаклашу һәм фикер алышу өчен бер мәйданга җыелды.

– Телебезнең чишмә башы – сездә, – дип башлады сүзен фестивальдә катнашкан Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары, комиссия җитәкчесе Марат Әхмәтов. – Телебезнең язмышы белән шөгыльләнә башлагач, аны тирәнрәк өйрәнә торгач, укытучылардан, тәрбиячеләрдән башка берни дә эшләп булмый, дигән фикергә килдек. Үзегезнең һөнәри осталыгыгызны никадәр нәтиҗәле, үтемле итеп балаларга тапшырып, аларның күңеленә сала аласыз, шул дәрәҗәдә туган телебез сакланачак. Тырышып, милләтебезгә, телебезгә хезмәт итүегезне теләп калам.

«Бала-Сити» балалар бакчасы генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты Альбина Насыйрова әйтүенчә, әлеге җыен аның күптәнге хыялы булган. «Иң сәләтле, креатив татар теле тәрбиячеләрен бергә җыеп, алар белән иркенләп аралашасы, тәҗрибә белән уртаклашасы килде. Фестивальгә республикабыздан гына түгел, Мәскәүдән һәм Төркиядән коллегаларыбызның килүе дә аеруча сөендерә. Димәк, бу – бик кирәкле чара. Килергә теләүчеләр бик күп иде, гаризалар кабул итү кампаниясе башланган көнне үк 180 укытучыдан гариза килде. Тик урыннар чикле булу сәбәпле, аларның барысын да кабул итә алмадык. Дәвамлы булып, әлеге фестиваль бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне алдыннан тагын бер матур традициягә әйләнер дип ышанам», – диде ул.

Фестивальгә килгән һәр тәрбияче үзен кызыксындырган төрле остаханәләрдә катнаша алды. Алар балалар бакчаларында заманча татар музыкасын куллану алымнары, балалар сөйләмен үстерүдә театр эшчәнлеге, интерактив технологияләрне куллану һәм башка кызыклы методикалар белән таныштылар.

– Бүген татар телен кызыклы итеп укыту өчен мөмкинлекләр күп. Бала татар теле дәресләренә теләп йөрергә тиеш. Шуңа күрә дә без үз эшебездә балаларны мавыктыра торган алымнар кулланабыз. Сабыйлар белән татар әкиятләрен сәхнәләштерәбез, хәрәкәтле уеннар уйныйбыз. Телне өйрәтүнең бу – иң нәтиҗәле ысулы, – диде «Бала-Сити» күптелле балалар бакчасының татар теле тәрбиячесе Ләйсән Вәлиева.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебез очкычлар төзү тармагын үстерүдәге аеруча күренекле казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «ЭНИКС» акционерлык җәмгыяте генераль директоры – баш конструкторы **Побежимов** Валерий Николаевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы **Гафаров** Марат Ринат улы, хезмәт ветераны **Лисица** Владимир Александрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Сентерева** Тамара Даниловна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең оештыру һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы урынбасары **Антонова** Юлия Евгеньева, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы аппараты гомуми бүлеге башлыгы **Әхмәтҗанова** Розалия Исхак кызы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгы **Әхмәтшин** Алмаз Сәлим улы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы **Бешенов** Валерий Владимирович, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Вәлиева** Мәдинә Гарифулла кызы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру эше бүлеге башлыгы урынбасары **Вафина** Зөлфия Ягъфәр кызы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары **Дроздецкая** Ольга Александровна, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы **Исламова** Рәисә Раиф кызы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы **Крайнова** Ирина Викторовна, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Ларионова** Валентина Александровна, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы **Маркова** Марина Юрьевна, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгы **Мөхәммәдиева** Азия Әсхәдулла кызы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлеге башлыгы **Мөхәммәтҗанова** Зөбәйдә Ризатдин кызы, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» муниципаль казна учреждениесенең мэр (Шәһәр Советы) эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы **Низамова** Фәридә Каим кызы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең икътисади үсеш бүлеге баш белгече **Сабирова** Наталья Анатольевна, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге башлыгы **Степанов** Сергей Николаевич, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы I категорияле белгече **Һадиева** Гөлнур Шамил кызы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шөңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Һадиева** Нурия Нургаян кызы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Шәйдуллин** Илфат Нәгыймулла улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәре Идел буе районының «22 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хор һәм вокал классы буенча укытучысы **Абдуллина** Гөлназ Талип кызына, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Бөгелмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе укытучысы **Бадыкшанова** Әлфия Ильяс кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Янгын сүндерү сынау лабораториясе» федераль янгынга каршы көрәшү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча суд-эксперт учреждениесе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы **Әхмәтҗанов** Марат Рафаэль улына, «Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча шартнамәле бүлекчәләре идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең 31 номерлы отряды янгын сүндерү-коткару часте башлыгы **Гурьянов** Сергей Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе законнар проектлау бүлеге баш киңәшчесе **Вәлиуллина** Лилия Камил кызына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Габделхаков** Марсель Мансур улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең философия һәм хокук кафедрасы мөдире **Нәҗметдинова** Фәридә Тансык кызына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты чит телләрне укыту теориясе һәм практикасы кафедрасы профессоры **Солнышкина** Марина Ивановнага, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең Россия фәннәр академиясенең «Гомуми тарих институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе базасындагы тарих һәм җәмгыять белеме кафедрасы доценты **Хораськина** Резида Илгиз кызына, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең инженерлык педагогикасы һәм психологиясе кафедрасы мөдире **Шаһиева** Фәридә Таһир кызына **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсенең Интернет челтәрендә наркотиклардан янаган куркынычка каршы көрәшү һәм наркотиклардан кергән керемнәрне легальләштерү бүлеге башлыгы урынбасары, полиция майоры **Имамов** Марат Илдар улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства от 21.01.2004 № 24 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан https://mpt.tatarstan.ru/ao-tatenergosbit.htm и АО «Татэнергосбыт» http://tatenergosbyt.ru/regulatory-filings/investment-info размещена в полном объеме информация о проекте инвестиционной программы АО «Татэнергосбыт» на 2023–2025 гг.

«Җырла, милләт! Җырла, Республика!»

«Болгар радиосы» «Җырла, милләт! Җырла, Республика!» бәйгесен игълан итте! Үзешчән, һәвәскәр башкаручылар арасында узучы бәйгедә атна саен бер җиңүче билгеләнәчәк! Ә иң яхшы җырлар «Болгар радиосы»нда яңгыраячак! Төп җиңүчегә – тәкә! Җыр батырына бүләкне радио алып баручылары үзләре алып килеп тапшырачак!

Бәйге шартлары:

1. Башкарган җырыгызны аудиоформатта яздырыгыз.

2. «Болгар радиосы» сайтының «КОНКУРСЫ» бүлегендә беркетелгән махсус анкетаны тутырыгыз.

3. ҖЫР ҺӘМ АНКЕТАНЫ bolgarradioisi@mail.ru электрон почтасына җибәрегез!

Җырлар 25 майга кадәр кабул ителә!

Һәр атна 1 җиңүче билгеләнәчәк. Атна җиңүчесе башкаруындагы җыр һәр пәнҗешәмбе 08.30 сәгатьтә «Болгар радиосы» дулкынында яңгырачак!

27 май – 1 июнь аралыгында сәнгать советы җиңүчеләр арасында бәйгенең 1 төп җиңүчесен билгеләячәк!

2 июнь көнне «Иртәнге чәй» тапшыруында җыр батыры игълан ителәчәк!

Тулырак мәгълүмат монда bolgarradio.com сайтында!

Хәзерге көндә бәйгедә катнашу өчен үзләренең җырларын төрле һөнәр ияләре җибәрде. Алар арасында лаеклы ялга чыккан полиция хезмәткәре, кондитер, йөртүче бар. Сезнең дә җырга сәләтегез бар һәм күптәннән үзегезне радиодан ишетергә телисез икән, бу – сезнең мөмкинлек! Катнашырга ашыгыгыз!

(16+)

Спорт

rubin-kazan.ru

Ниһаять!

«Рубин»ның 7 марттан бирле җиңә алган юк иде. Грозныйда «Ахмат»ны откannан соң Казан командасы, дүрт мәртәбә җиңелеп, бер мәртәбә ничьяга уйнады. Ниһаять, Леонид Слуцкий футболчылары 3 очкога ия булды. Якташларыбыз үз кырында премьер-лиганың иң көчсез командасы булган «Арсенал»дан өстен чыкты.

«Рубин» файдасына 1:0 исәбе белән тәмамланган очрашуда Казан командасының 3 уенчысын аерым телгә алу урынлы булыр. Капкачы Юрий Дюпин бу сезонда тәүге мәртәбә очрашуны бер туп та керттерми тәмамлады. Кышкы тәнәфестә «Рубин»га килеп кушылган Александр Ломовицкий беренче тубын кертте. Узган елдан бирле чыгыш ясамаган Оливер Абильдгор, ниһаять, уен кырына чыкты һәм командага көч өстәде. Дания футболчысы – мәгълүм вакыйгалар аркасында клуб белән килешүен туктатып, туган ягына кайтып китмәгән ике чит ил уенчысының берсе. «Теләсә нинди җиңү рухи яктан ярдәм итә. Җиңелү үтерә, ә җиңү канат куя», – диде очрашудан соң Леонид Слуцкий.

	команда	очко
1	Зенит	55
2	Динамо	52
3	ЦСКА	47
4	Сочи	46
5	Локомотив	41
6	Краснодар	39
7	Крылья Советов	38
8	Ростов	34
9	Ахмат	32
10	Спартак	31
11	Рубин	29
12	Нижний Новгород	28
13	Химки	28
14	Урал	24
15	Уфа	22
16	Арсенал	21

Арча

Моннан берничә ел элек Арча мәдәният йорты каршындагы мәйданда район кулибиннары ясаган авыл хуҗалыгы техникасы күргәзмәсе оештырганнар иде. Хәтта мини-комбайннарга хәтле бар иде анда. Эшкә бик хирыс безнең халык. Шундыйларның берничәсе белән якыннан танышырга ниятләп, туган якларга кузгалдым. Күптәнге дустым, умартачы Ядкарь Мөхәммәдиев бервакыт: «Безнең авылда да тимер җене кагылган биш-алты егет бар. Кил, үзем таныштырырмын», – дигән иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТИМЕР ҖЕНЕ

Каршы алды ул безне туган авылы Түбән Атыда. Урамнарда, шаулап, гөрләвекләр ага, минем машина бөтен җирдән уза алмас дип, без Ядкарьнең «УАЗ-патриот»ына кереп утырдык. «Без» дип «Арча хәбәрләре» газетасы хезмәткәре Ильяс Фәттаховны да күз алдында тотып язуым иде.

Ильяс юлда барганда ук, кулибиннарның районда бик ишле булуын әйткән иде. Аларның санын төгәл генә әйтә алмады, йөздән артык дип язсаң ялгышмассың, диде. Район газетасы авыл хуҗалыгы идарәсе белән берлектә Арча уйлап табучылары арасында бәйге игълан иткән икән, хәзер алар ясаган техниканың рәсемнәрен кабул итәләр. Язгы кыр эшләре тәмамлангач, техника парады оештырмакчылар. Кем әйтмешли, күрәселәр бар икән әле.

Ядкарь безне иң әүвәл Ризуан Гатауллин янына алып барды, башкалары эштә булып чыкты. Ризуан Урта Атыда яши, Түбән Аты белән бу авылны һаман да буташтырам әле. Чөнки аларны инеш аша салынган кечкенә күпер генә аерып тора. Ике авыл арасы нибары унбиш-егерме адым булыр. Бер-беренә елышып дигәндәй утырган мондый авыллар бүтән юк бугай ул. Арчада гына түгел, бөтен Татарстанында, диюем. Һәм икесенә бергә биш-алты кулибин яшәгәннәре дә юк. Әле уйлап табучылар саны артуга да бара икән. Ризуанның оныгы Айназ да – тимер җене кагылган егет. Күптән түгел бер иске матай сатып алып, үзе сүтеп җыйган. Кыскасы, бабасы шөгыленә яшьли күңеле төшкән. «Дөрес кеше» булыр өчен, һәркем ни белән булса да шөгыльләнергә тиеш, дип саный Ризуан. Үзе гомер буе колхозда трактор, комбайнда эшләгән, шул ук вакытта нәрсәдер уйлап табарга, нидер ясарга тырышкан. Колхозлар таралгач та аптырап калмаган, сигез сыер асрый башлаган һәм хатыны Розалиягә эшне җиңеләйтү өчен, саву аппараты ясап биргән. Аннан соң он тарту өчен тегермән дә ясаган. Безне лапаска алып кереп, анысын да күрсәтте. «Кибеттән алган тегермән моның янында чүп кенә, ә дигәнче биш чиләк он чыгара да куя», – ди. Ташландык суыткыч моторыннан компрессорлар да ясап куйган. Сарае тулы тимер-томыр, иң кызыгы: һәрберсенә кирәк урын таба Ризуан.

Мин аның исемен «Ризван» дип язмакчы идем, юк, паспорттагыча булсын, диде. «ВКонтакте» аккаунтында да, «Ютуб» каналында да Ризуан дип язылган. «Исемне бозып язсаң, мине таба алмаячаксың», – дип кисәтеп тә куйды егетебез. Дөресен әйткәндә, миңа бераз оят булып китте. Гомер буе редакцияләрдә эшләп, интернеттан Ризуан кебек файдаланганым юк. Ул, үзе ясаган мотоблокларны, мини-тракторларны рәсемгә төшереп, социаль челтәрләргә, «Ютуб» каналына куя, ерак чит илләр үк булмаса да, элек СССРга кергән союздаш республикаларда яшәүчеләр белән аралаша икән. Тегеләре моннан киңәш сорап язалар, ди. Ә күрше-тирә авыллар тәҗрибә уртаклашырга килә. Кыскасы, кеше өзелми аның яныннан.

Без килгәндә дә бер яшь кенә егет бар иде. Таныштык. Фәнил исемле икән, фамилиясе – Кәримов. Казанда Теннис академиясендә слесарь-сантехник, эретеп ябыштыручы булып эшли. Казанга эшкә өч көнгә бер бара һәм буш көннәрен авылда тимер-томыр арасында уздыра. Быел беренче мәртәбә мини-трактор ясаган һәм карап китә алмас микән дип, Ризуан абыйсы янына килгән. Ә тегесе шаярткан була, янәсе, аяклар да авыртып тора, сиңа хәтле барып җитеп булмас. «Үзем күтәреп алып менәм, өеңә хәтле күтәреп алып төшәм», – ди Фәнил, елмаеп. Ризуанның ярдәмсез калдырмаячагын белә ул. Ядкарь машинасында бардык Фәнилгә. Остазы аңа үз киңәшләрен бирде. Игътибар белән тыңласам да, аларның сөйләшкәннәрен бик үк аңлап бетермәдем. Үзләренә генә хас телләре бар кебек тоелды.

Бер уйлаганда, мини-трактор бик үк катлаулы механизм түгел кебек. Әмма Ризуан аны үзенчә бөтенләй үзгәртеп бетергән. Детальләрендә чит телдә язулар шактый. Кыскасы, бу авылдагы мини-тракторлар бер «җыелма образ» кебек. Ризуан әйтүенчә, мәсәлән, кибеттән сатып алган техника бернәрсәгә дә ярамый.

– Алай булгач, нигә эшләп чыгаралар соң аларны? – дим.

– Акча эшләү өчен, – ди Ризуан. Аның сүзләре белән килешеп бетәсе килми. Әмма гел үзенекен тукый егет. «Тәмам камилләштереп бетермичә, эшкә яраксыз алар», – ди. Белмим, бәлки, арттырадыр да. Әмма тракторның нинди детальләрен алыштыруы, нәрсә өстәүләре турында сөйли башлагач, ышандыра тагын. «Кибеттән алганда, хәтта двигательне каплап бетерерлек капоты да, тәгәрмәчләрнең крылолары да юк иде», – ди. Аның тракторлары «үзе суга, үзе җилгәрә» дигәндәй, күп төрле эшне башкара, өстәмә агрегатларны да үзе ясаган. Сукалый да, тырмалый да, печән дә чаба, чабылган печәнне төяп алып та кайта, бәрәңге дә утырта. Барысын да, үзе әйтмешли, кирәксез дип ташлаган тимер-томырдан эшли Ризуан. Мондый кешене «Кулибин» дими, кем дисең инде.

Сүз уңаеннан, Иван Кулибин турында безгә мәктәптә укыганда ук шактый мәгълүмат биргәннәр иде. 1735 елда Түбән Новгород губерниясенең бер авылында вак сәүдәгәр гаиләсендә туган Иван Петрович Кулибин үз заманасының атаклы уйлап табучысы, механигы исәпләнгән. Үсмер чагында ук үзлегеннән слесарьлык, токарьлык һөнәренә өйрәнгән ул. 34 яшендә инде Петербург Фәннәр академиясенең механика остаханәсе мөдире итеп билгеләнгән. Күпер проектлары, механик суднолар, искитмәле автоматлар эскизлары, педаль әйләндереп хәрәкәткә килә торган машиналар, тагын әллә нәрсәләр уйлап тапкан бу шәхес, мәгълүм фильмда Чапаев әйтмешли, «академиев не кончал», ул халык арасыннан чыккан уйлап табучы булган. Бәлки, чагыштыруым бик урынлы да булмас, Урта Аты егете Ризуан да махсус белем алмаган. Арча кулибиннары, гомумән, табигать биргән талантка ия. Ризуан да бернинди сызымнарсыз эшли.

«Кайвакыт тәмәке тартып утырганда да башка уй килә. Бу техниканы тагын да камилләштерергә була бит, дип сүтә, кайбер механизмнарын үзгәртә башлыйм», – ди. Мәсәлән, басу юлларында тизрәк йөрсен өчен, дизель двигателен бензинга көйләү аның өчен берни дә тормый. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен, үзе әйтмешли, модернизировать итми булмый. «Кыш уздыру ай авыр!» – дип зарланып алды әле. Чөнки җылы остаханәсе юк, ә баш та, куллар да эш сорый. Эшсезлектән авыруга сабышам, ди. Тимер белән эшли башлауга бөтен сырхаулары юкка чыга икән.

Җылы язны, җирнең кардан арынуын көтеп яши Ризуан, тизрәк үзе ясаган техникага утырасы килә. Тормыштан зарланмый ул. Хатыны Розалиягә дә: «Нинди генә еллар килсә дә, ачка үлмәячәкбез», – ди икән.

Тик менә бер нәрсә борчый аны. «Авыл халкы, бигрәк тә безнең татар бик тырыш, эшчән бит ул. Терлек тә асрый, җиләк-җимеш, яшелчә дә үстерә. Артыгын сатасы да килә, тик мөмкинлекләр чикле. Безгә дәүләт ярдәме җитми», – дип куйды.

Бу – күптән килгән «койрыклы» проблема. Элекке заготконторалар бетте, алар урынына кооперативлар оештыру турында сүз чыккалый үзе, тик чыккалый да бетә. Безгә Мисыр бәрәңгеләре кайтару отышлырак микәнни, дип тә уйлап куям. Ә хәзергә авыл халкы эшли әле, аның авыл хуҗалыгы продукциясен, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру белән кызыксынучы, бакча эшләрендә авылдашларына бушлай ярдәм итәргә торучы кулибиннары да бар. Ә иртәгә нишләргә? Авыл бетә, дип зарланып утырганчы, аңа ярдәм кулы сузсак, әйбәтрәк булыр иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

АТЛАГАН САЕН ӨМЕТ АРТА

Кайсыгызның кулы җылы?

«Акча җыяр өчен счет ачу җиңеллләрдән бирелмәде. Социаль челтәрләргә реквизитларны куйганчы мең кат уйладык. Чөнки хәле безнекеннән күпкә авырраклар да күп. Моңа кадәр кызыбыз турында чит-ятларга әйткәнебез булмады. Ләкин сәламәтләнер өчен, яхшы табибларга күренергә, кыйммәтле дәвалану курслары узарга кирәк. Шуңа күрә тәвәккәлләргә булдык».

Казанда яшәүче 3 яшьлек Таңсылуның әнисе Алисә Закирова башкаларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итүен, кыенсынып кына, әнә шулай дип аңлата. Моңа кадәр алар болай да бар авырлык-мәшәкатьне сабыр гына үз җилкәләрендә күтәргән. Ана кеше, гаиләсенә язылган сынауны да, күңелендә саклап, берничә ел чит-ятларга белгертмәде.

Кызчыкның әнисе Алисә белән «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә бергә эшләдек. Шуңа күрә аның бәгырь җимешен ничек зарыгып көтүе, нарасыен карынында йөрткәндәге мәшәкатьләре – барысы да күз алдында булды. Чыннан да, Таңсылу – әти-әнисенең сөеп, көтеп алынган көдрә чәчле, яратып туя алмас матур кызлары.

– Кызыбыз вакытыннан алда, 34 атналык чагында туды, – дип искә ала ул көннәрне Алисә. – Хастаханәгә кергәндә, анализларым начар, балага һава җитми иде. Хәлемне чамалап, баламны ярып алуларын үтендем, тик табиблар, кырт кисеп: «Үзең табасың», – диделәр. 10 сәгать авырганнан соң, кыенлык белән Таңсылуны үзем таптым. Балам 1970 грамм булып туды. Буе да кыска иде. Карында вакытта гипоксия кичергәнлектән, баш миенә кан сауганлыгын соңрак белдек. Ана булу шатлыгын кичерер урынга табиблардан бер кочак диагноз ишетергә туры килде.

Шуннан соң ана белән бала бер ай хастаханәдә дәвалана. Кызчыкның тормышының беренче көннәре, айлары авыр булса да, алга таба хәле яхшыра. Калган балалардан берничә айга соңга калып булса да, утыра, үрмәли, авазлар чыгара. 1 яшь тә бер айда әти-әнисен сөендереп, тәүге адымнарын да ясый. Тик тәпи киткәч, бер ай узуга, бер аягына дөрес басмавына игътибар итеп, баланы табибка алып баралар. Башта ортопед, яшь әти-әнине тынычландырып, ныклап йөреп киткәч, барысы да узар, ди. Тик тагын берничә айдан соң табиблар баланың аягында кимчелек барлыгын раслый.

Алисә Закированың шәхси архивыннан

– Күпмедер вакыттан соң кызыбызның уң аягы бер сантиметрга кыскарак булу, уң кулы да начаррак эшләве ачыкланды. 1,5 яшьтә уң якта гемипорез дигән диагноз куйдылар. МРТ нәтиҗәләре баш миендә киста барлыгын күрсәтте. Дәвалар алсак та, үзгәреш булмады. 2 яшен тутыргач, ДЦП диагнозы куйдылар. Әлеге авырлыкларны баш миенә кан саву белән аңлаталар, – ди Алисә.

Мондый авыр диагнозны ишеткәч, әни кеше аптырашта кала.

– Без ДЦП диагнозлы балаларның хәле бик авыр була, дип күзалларга күнеккән. Тик аның төрле дәрәҗәсе була икән. Карап торышка кызыбыз башка балалардан берни белән дә аерылмый. Шундый ук шук, шаян. Йөри, йөгерә, уйнарга, рәсемнәр ясарга ярата, аралашучан, акылы да сау-сәламәт. Тик аяклары бик тиз арый, еш кына сөртенеп егыла, аксый. Аягы авыртудан зарланып, елап уянган төннәре дә бар. Шуңа күрә, җиңеллек булсын өчен, әледән-әле дәвалану узып торабыз. Баштагы вакытларда дәвалануларның файдасы булыр да, барысы да артта калыр, дип уйлый идек. Тик вакыт барган саен, уңай үзгәрешләр күзәтелмәде, – ди Алисә.

Апрельдә алар Кырымда дәваланып кайтканнар.

– Анда нәкъ менә шундый балаларны уңышлы дәвалыйлар, тәҗрибәләре зур, табиблар да, тернәкләндерү дә көчле. Безнеке кебек диагнозы булганнарның күпчелеге операцияләрне шунда барып ясата. Чыннан да, дәваланудан соң уңай үзгәрешләр күрәбез. Йөрүе җиңеләйде, тонусы кимеде. Ләкин болар барысы да вакытлыча гына, – ди кызчыкның әнисе.

Алга таба Таңсылуны бик күп дәвалану курслары, зур операция көтә. Мин шалтыратканда да, Алисәнең кызы белән анализлар биреп кайтып килеше иде. Кабат Кырымга китәргә әзерләнәләр.

– Операцияне дә шунда ясатырга туры киләчәк. Аның вакыты әлегә төгәл билгеле түгел. Ләкин никадәр алданрак ясатсак, шуның кадәр яхшырак. Чөнки кызыбыз аягына дөрес басмау аркасында, аяк табаны дөрес формалашмый. Катлаулы операцияне тормышны мәҗбүри иминиятләштерү полисы буенча бушлай ясаячаклар. Аннан соң иң авыр һәм җаваплы чор – тернәкләнү башлана. Операциядән соң тернәкләндерүнең ике атнасы гына бушлай. Бу гына җитмәячәк, әлбәттә. Таңсылуга яңадан йөрергә өйрәнергә туры киләчәк. Шуңа күрә операциядән соңгы тернәкләндерү чыгымнарының күпчелеген үзебез күтәрәчәкбез. Әле аннан соң да даими рәвештә тернәкләнү узып торырга туры киләчәк. Операция, дәвалану тиешле дәрәҗәдә узган очракта, кызыбыз өчен авыртуларсыз, матур тормыш башланыр, дигән өметебез зур, – ди әни кеше.

Закировларга булышырга теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:

Әнисе Алисә Рәнис кызы Закирова исемендәге

Саклык банкы картасы: **4817 7602 0795 6503,**

Тинькофф банкы картасы: **5536 9140 4710 9982,**

«Ак барс» банкы картасы: **4000 7934 7675 9289.**

Әлеге карталар **89991637874** телефон номерына беркетелгән.

Хәбәрләшү өчен телефон номеры: **89172554853.**

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 259

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+